Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Түнтәр авылы торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

13 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегенең Түнтәр торак пунктында халык җыены Карар кабул итте:

1. «95% күләмендә ташлама билгеләнгән Бөек Ватан сугышы ветераннары, 1 төркем инвалидлар, балачактан инвалидлар, ялгыз өлкән пенсионерлар һәм өлкән яшьтәгеләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, Россия Армиясендә хезмәт итүчеләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 2025 нче елда үзарасалымны 600 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы әһәмиятле булган җирлек автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; торак пункт территориясен төзекләндерү - кабул ителгән.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Перфилов Ю. М.